**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның «30» декабреннән № 387

**«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 431 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының район Башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актлар юлламасы буенча һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен эшенең законнарда билгеләнгән тәртиптә, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарының

муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 30 декабрендәге 70 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен эшләве Регламентның үтәлүен билгеләргә.

2. Регламентта һәм законнарда билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җыярга һәм аларны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җыю һәм җибәрү өчен җаваплы зат итеп Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүчесен билгеләргә.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе вакытлыча булмаган очракта, әлеге карарның 3 пунктында каралган вәкаләтләрнең Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдире исеменә йөкләнүен билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты житәкчесе** **Р.Р. Фасахов**